ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТА-ЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 1** **14 март 2024 ел**

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Кече Урыссу торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләренә,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 ноябрендәге 28 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләренә ярашлы рәвештә, татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 октябрендәге 17 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмәнең 4.4 пунктчасы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 25 мартында 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Кече Урыссу авылы, Совет урамы, 21а адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында, 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:

2.1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2023 елның 27 октябрендәге 4 санлы гражданнар җыены карарын гамәлдән чыгарырга ризамы?

2.2. "Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә ризамы, һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлтүгә ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамы буенча юл-урам челтәрен ремонтлау (Кече Урыссу торак пунктында асфальтлаштыру, вак таш җәяү, материаллар, җиһазлар, транспорт хезмәтләре сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев